**Татарстан Республикасы һәм Белгород өлкәсе арасында икътисадый, мәдәни, социаль һәм башка өлкәләрдә хезмәттәшлек турында килешү**

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Президенты Миңнеханов Рөстәм Нургали улы йөзендә Татарстан Республикасы, бер яктан, һәм Белгород өлкәсе Уставы нигезендә эш итүче Белгород өлкәсе Губернаторы Савченко Евгений Степанович йөзендә Белгород өлкәсе, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталып,

Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм Белгород өлкәсе законнарына (алга таба – законнар) таянып,

тигез хокуклылык һәм үзара файда принциплары нигезендә төбәкара элемтәләрне үстерү, Россия Федерациясендә сәяси һәм икътисадый үзгәрешләрне исәпкә алып, хезмәттәшлекнең хокукый нигезләрен ныгыту максатларында,

үзара файдалы хезмәттәшлекне киңәйтү Татарстан Республикасы һәм Белгород өлкәсе халкы мәнфәгатьләренә җавап бирүен һәм Татарстан Республикасының һәм Белгород өлкәсенең икътисадый үсешенә ярдәм итүен танып,

үз хокукларын һәм вәкаләтләрен Россия Федерациясенең тигез хокуклы субъектлары буларак гамәлгә ашырып,

ике яклы элемтәләрне тотрыклы нигездә һәм озак вакытка исәп тотып үстерүгә үзара кызыксыну белдереп һәм моның өчен тиешле оештыру, икътисадый, хокукый һәм башка кирәкле шартлар булдырырга теләп, түбәндәгеләр турында килеште:

**1 статья**

Яклар хезмәттәшлекне үзара хөрмәт, тигезлек, партнерлык һәм икътисадый файда нигезендә үстерә.

Яклар үз вәкаләтләре кысаларында мөнәсәбәтләрне төрле яклап үстерү өчен уңай шартлар тудыра.

Законнар нигезендә һәм бирелгән вәкаләтләре кысаларында Яклар Татарстан Республикасы һәм Белгород өлкәсе территорияләрендә теркәлгән һәм хуҗалык эшчәнлеге алып баручы юридик затларның, эшкуарларның (алга таба – хуҗалык субъектлары) хезмәттәшлегенә ярдәм итә.

**2 статья**

Яклар бер-берсенә икътисадый яисә башка төрле зыян китерердәй гамәлләрдән тыела, аларны кабул итү Якларның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылырга мөмкин булган карарларны килештерә һәм алар турында мәгълүмат алмаша.

**3 статья**

Сәүдә-икътисадый, инвестиция һәм инновация хезмәттәшлеге өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

хуҗалык субъектлары эшчәнлеге, шулай ук икътисад өлкәсенә Якларның икесенең дә кызыксынуын уяткан инвестицияләр кертү өчен уңайлы шартлар тудыра;

хуҗалык субъектлары арасында сәүдә-икътисадый элемтәләрне үстерүгә ярдәм итә;

хуҗалык субъектлары арасында кооперация элемтәләрен киңәйтүгә ярдәм итә;

җитештерү-техник билгеләнештәге продукциянең кирәкле төрләрен, халык куллану товарлары һәм азык-төлек товарларын китертүне гамәлгә ашыруга ярдәм итә;

Татарстан Республикасының электрон ресурслары үсешенә ярдәм итә;

Татарстан Республикасының һәм Белгород өлкәсенең икътисадый һәм инновация потенциалын үстерүгә юнәлтелгән уртак проектлар эшли, Якларның икесендә дә кызыксыну уяткан тармаклар буенча проектлар һәм белгечләр алмаша;

хуҗалык субъектлары арасында эшлекле элемтәләр урнаштыру һәм киңәйтү өчен шартлар тудыруга, Татарстан Республикасында һәм Белгород өлкәсендә эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм итү программаларын эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга ярдәм итә;

«Татарстан Республикасының төбәк лизинг компаниясе» акционер җәмгыяте продуктлары турында һәм әлеге продуктлар кысаларында лизинг финанславы алу мөмкинлекләре турында Белгород өлкәсе кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мәгълүматлылык дәрәҗәсен күтәрә;

фән, технологияләр һәм инновацияләр өлкәсендә элемтәләрнең нәтиҗәле системасын формалаштыруга, шулай ук икътисадның реаль секторы белән тикшеренүләр һәм эшләнмәләр секторының үзара хезмәттәшлеген, шул исәптән «Инноскоп» Россия ачык инновацияләр үзәге» интернет-порталы аша да, булдыруга ярдәм итә;

инвестиция һәм инновация эшчәнлеге өлкәсендә хезмәттәшлек итә, шул исәптән Татарстан Республикасының һәм Белгород өлкәсенең икътисадын үстерү һәм конкурентлыкка сәләтен арттыру максатында инвестицияләр кертү өлкәсендә активлыкка этәргеч бирү чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, бизнес-миссияләр, инвестиция мәйданчыкларын һәм инвестиция потенциалын презентацияләүне оештыра, рәсми визитлар һәм эшлекле очрашулар кысаларында инвестиция проектларын тормышка ашыру буенча тәҗрибә уртаклаша, Татарстан Республикасы һәм Белгород өлкәсе территорияләрендә инвестиция форумнары, конференцияләр һәм инвестицияләр юнәлешендәге башка чаралар үткәрү турында хәбәр итә;

инвестиция проектларын тормышка ашыруның иң нәтиҗәле рәвешләрен билгеләп, мәгълүмати-аналитик тәэмин итү системасын үстерә;

дәүләт-шәхси партнерлык механизмнарын үстерә;

Татарстан Республикасының һәм Белгород өлкәсенең норматив хокукый актлары һәм аларның инвестиция эшчәнлеген үстерү өлкәсендәге проектлары турында мәгълүмат алмаша;

Яклар арасында транспорт элемтәсен үстерүгә ярдәм итә;

әлеге Килешүдә билгеләнгән хезмәттәшлек юнәлешләре буенча уртак күргәзмәләр, конференцияләр, семинарлар, киңәшмәләр, түгәрәк өстәлләр, презентацияләр һәм башка чаралар уздыруга булышлык итә;

төбәкара һәм халыкара азык-төлек һәм сәнәгать товарлары күргәзмәләрен һәм ярминкәләрен оештыру һәм уздыру планнары белән алмаша, Яклар вәкилләренең һәм кызыксынган хуҗалык субъектларының аларда катнашуына ярдәм итә.

**4 статья**

Авыл хуҗалыгы, дәүләт ветеринария күзәтчелеге һәм хайваннар сәламәтлеге өлкәсендә үз вәкаләтләре чикләрендә һәм законнар нигезендә кирәкле оештыру шартларын булдыру юлы белән Яклар түбәндәге юнәлешләр буенча ярдәм күрсәтә:

үсемлекчелек, селекция, орлыкчылык, алдынгы технологияләрне, үсемлек генофондын, бөртекле һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын эшкәрткәндә үсемлекләрне саклау чараларын һәм экологик яктан чиста ысулларны бергәләп куллану, игенчелекнең һәм туфракны саклауның экологик-ландшафт системасын гамәлгә ашыру;

заманча технологияләр нигезендә терлекчелек, продукция бирүе югары дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы терлекләрен үрчетү, асрау һәм ашату, механикалаштырылган фермаларны техник яктан яңартуга ярдәм итү;

биотехнология, авыл хуҗалыгы культуралары җитештерүгә һәм хайваннар үрчетүгә биотехнологик идарә;

эшкәртү, азык-төлек сәнәгате, җитештерү процессын механикалаштыру һәм автоматлаштыру чараларын комплекслы файдалану.

**5 статья**

Яклар сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлар турында фәнни-гамәли мәгълүмат алмашуга, халыкның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге алдынгы тәҗрибәне өйрәнү һәм Татарстан Республикасы һәм Белгород өлкәсе территорияләрендә күрсәтелә торган медицина ярдәменең сыйфатын яхшырту максатларында делегацияләр алмашуга ярдәм итә.

Яклар Татарстан Республикасы һәм Белгород өлкәсе территорияләрендә үткәрелә торган фәнни-гамәли конференцияләрдә, семинарларда һәм махсуслаштырылган күргәзмәләрдә Татарстан Республикасының һәм Белгород өлкәсенең кызыксыну белдергән белгечләренең катнашуына ярдәм итә.

**6 статья**

Социаль яклау һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы һәм Белгород өлкәсе:

халыкны эш белән тәэмин итү, халыкка социаль ярдәм һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә, шул исәптән әлеге өлкәләрдә норматив хокукый актлар кабул итү һәм аларны үтәү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлекне үстерә, социаль-икътисадый үсеш программаларын, гаиләгә, аналарга, балаларга, өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү программаларын гамәлгә ашыру буенча үзара хезмәттәшлек итә һәм тәҗрибә уртаклаша;

яңа социаль технологияләрне куллануга кертүгә кагылышлы эш тәҗрибәсен өйрәнү өчен социаль яклау органнары, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре делегацияләре алмаша;

эшсезлеккә һәм хезмәт базарындагы хәлгә бәйле мәгълүмати-аналитик материаллар алмаша.

**7 статья**

Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

Татарстан Республикасында һәм Белгород өлкәсендә әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү мәсьәләләре буенча үткәрелә торган халыкара хезмәттәшлек турында мәгълүмат алмаша;

аерым саклана торган табигать территорияләре, кызыл китапларны алып бару, хайваннар дөньясы объектларын, су биоресурсларын саклау һәм куллану өлкәсендә хезмәттәшлек итә;

җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, калдыкларны сортларга аеру, эшкәртү һәм утильләштерүнең яңа технологияләрен куллануга кертү, аеруча саклана торган табигать территорияләрен оештыру һәм эшләтү, табигатьне саклау структураларына идарә итүне камилләштерү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итүгә һәм тәҗрибә алмашуга ярдәм итә.

**8 статья**

Мәдәният өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

аларда Яклар коллективларына һәм башкаручыларына катнашу мөмкинлеге бирү максатларында Татарстан Республикасында һәм Белгород өлкәсендә узачак мәдәни вакыйгалар һәм чаралар турында, шул исәптән халыкара дәрәҗәдә уздырыла торганнары турында да, мәгълүмат алмашуны гамәлгә ашыра;

мәдәни элемтәләрне ныгытуга һәм үстерүгә булышлык күрсәтә;

иҗат коллективларының гастрольләрен, музей, сәнгать һәм китап күргәзмәләрен оештыру мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

мәдәни мирас объектларын саклау, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек итә һәм тәҗрибә уртаклаша.

**9 статья**

Архив эше өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

архив эше өлкәсендә архив органнары һәм учреждениеләр эшчәнлегендә кулланыла торган норматив һәм методик эшләнмәләр, мәгълүмати технологияләр турында тәҗрибә һәм мәгълүмат алмашуны гамәлгә ашыра;

фәнни-гамәли конференцияләрне, семинарларны, киңәшмәләрне, архив документлары күргәзмәләрен оештыруда һәм үткәрүдә, Россия Федерациясе Архив фонды документлары буенча басмалар әзерләүдә катнаша;

тикшеренүләр һәм гражданнарның социаль-хокукый ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле архив документлары һәм фәнни-белешмә материаллардан законнар нигезендә файдалану мөмкинлеген булдыруга бер-берсенә ярдәм итә.

**10 статья**

Мәгариф һәм фән өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

уртак конференцияләр үткәрә;

уртак фәнни-тикшеренү проектларын гамәлгә ашыра;

белем бирү оешмалары эшчәнлеген җайга салучы заманча белем бирү технологияләрен, норматив хокукый актлар проектларын эшләү буенча тәҗрибә уртаклаша.

**11 статья**

Мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

мәгълүмат технологияләре өлкәсендә, шул исәптән төрле инвестиция проектларын гамәлгә ашыру юлы белән дә, үзара файдалы хезмәттәшлекне үстерә;

укытучылар, тикшеренүчеләр һәм башка фәнни-тикшеренү һәм административ персонал алмаша;

фәнгә нигезләнгән тармаклар үсешен, шул исәптән уртак предприятиеләр төзү яки технологик хезмәттәшлек һәм укыту юлы белән дә, стимуллаштыра.

**12 статья**

Спорт өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасының һәм Белгород өлкәсенең җыелма спорт командаларының спорт чараларында катнашуына ярдәм итә.

**13 статья**

Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

Яклар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган чараларда (форумнар, слетлар, семинарлар, фестивальләр, конкурслар) яшьләрнең катнашуына ярдәм итә;

креатив индустрияләрне үстерү өлкәсендә (булган очракта) үзара хезмәттәшлек һәм тәҗрибә алмаша;

яшьләрнең төрле категорияләре белән эшләүдә иң уңышлы тәҗрибәләрне гамәлгә ашыру буенча мәгълүмати-аналитик материаллар, методик тәкъдимнәр алмаша.

**14 статья**

Туризм өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

Татарстан Республикасының һәм Белгород өлкәсенең туризм өлкәсендә булачак чаралары турында мәгълүмат алмаша;

Татарстан Республикасының һәм Белгород өлкәсенең туристлык оешмалары арасында үзара элемтәләр урнаштыруда ярдәм итә.

**15 статья**

Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

төзелешне оештыру, шәһәр төзелеше сәясәте өлкәсендә һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә тәҗрибә уртаклаша;

төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт хакимияте органнары делегацияләре алмаша;

халыкара, республика һәм өлкә күргәзмәләрендә, төзелеш, шәһәр төзелеше һәм архитектура тематикасына багышланган семинарларда һәм конференцияләрдә катнаша.

**16 статья**

Милли сәясәт өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

Татарстан Республикасы һәм Белгород өлкәсе территориясендә яшәүче халыклар мәдәниятләренең якынаюына һәм үзара баюына ярдәм итә, тарихка һәм рухи кыйммәтләргә ихтирамлы мөнәсәбәт тәэмин итеп, туган телләрне, йолаларны һәм гореф-гадәтләрне саклап калуны гарантияләп, аларның милли-мәдәни мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү өчен кирәкле шартлар тудыра;

кара-каршы визитлар оештырганда, Татарстан Республикасы һәм Белгород өлкәсе территориясендә яшәүче халыкларның милли-мәдәни җәмгыятьләре җитәкчеләрен делегацияләр составына кертергә ярдәм итә.

**17 статья**

Әлеге Килешү аны имзалаган Якларга финанс яки милек йөкләмәләре салмый.

**18 статья**

Әлеге Килешүне гамәлгә ашыру максатларында Яклар шартнамәләр (килешүләр), чаралар планнары төзергә, хезмәттәшлекнең конкрет өлкәләрендә уртак чараларны гамәлгә ашырырга хокуклы.

Әлеге Килешү Якларның өченче яклар белән төзелгән шартнамәләре (килешүләре) буенча йөкләмәләренә кагылмый һәм аларның нинди дә булса мәнфәгатьләренә зыян килерлек итеп файдаланыла яисә өченче яклар алдында алынган йөкләмәләрен үтәү өчен киртә була алмый.

Аерым хуҗалык субъектлары эшчәнлеге өчен әлеге Килешү нигезләмәләре конкуренцияне чикләү яисә башка хуҗалыклар мәнфәгатьләрен кысу рәвешендәге нәтиҗәләргә китерергә мөмкин булган уңай шартлар тудыра алмый.

**19 статья**

Яклар әлеге Килешүне гамәлгә ашыру барышында килеп туган мәсьәләләрне тиз арада карап тикшерә һәм аларны уңай хәл итү буенча законнар нигезендә кирәкле чаралар күрә.

**20 статья**

Әлеге Килешүнең нигезләмәләрен шәрехләүдә һәм (яисә) кулланганда килеп чыгуы мөмкин булган фикер төрлелеген һәм бәхәсләрне Яклар сөйләшүләр һәм консультацияләр юлы белән хәл итә.

**21 статья**

Әлеге Килешү Татарстан Республикасының һәм Белгород өлкәсенең Килешүнең үз көченә керүе өчен кирәкле эчке процедураларны үтәүләре турында бер-берсенә җибәргән язмача хәбәрләре алынган көннән үз көченә

керә һәм биш ел дәвамында гамәлдә була.

Алга таба әлеге Килешүнең гамәле, әгәр дә Якларның берсе дә аның гамәлен туктатырга ниятләве турында язмача хәбәр итмәсә, үзеннән-үзе аннан соңгы биш еллык чорларга озайтыла.

Әлеге Килешүнең гамәле Якларның берсе тарафыннан Килешүнең гамәлен туктатырга ниятләве турында икенче Якның язма хәбәре алынганнан соң алты ай узгач туктатыла.

Әлеге Килешүгә үзгәрешләр Якларның уртак ризалыгы буенча әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган өстәмә килешүләр нигезендә кертелә.

Белгород шәһәрендә 2019 елның «28» декабрендә рус һәм татар телләрендә бер үк көчкә ия булган ике нөсхәдә, Якларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә башкарылды.

Терминнарның мәгънәсендә аерымлыклар яисә нинди дә булса туры килмәү очраклары килеп чыкса, рус телендәге текстка өстенлек бирелә.

| Татарстан Республикасы өчен | Белгород өлкәсе өчен |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Президенты | Белгород өлкәсе Губернаторы |
| Р.Н. Миңнеханов | Е.С. Савченко |

09.01.2020
№ 1